**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 11 ноябрь № 863

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 3 ноябрь, 832 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары торышына, эчтәлегенә, аларны саклауга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары торышына, эчтәлегенә, аларны саклауга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2015 ел, 3 ноябрь, 832 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары торышына, эчтәлегенә, аларны саклауга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 нчы пунктның 2 нче пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 ел, 24 ноябрь, ФЗ-181 нче Федераль закон нигезендә инвалидлар өчен мәдәни мирас объектларын файдалана алуны тәэмин итү чаралары».»;

9 нчы пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) һәм муниципаль тикшерүне гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 ел, 26 декабрь, ФЗ-294 нче Федераль законның $8^2$ һәм $8^3$ статьялары нигезендә чаралар үткәрү».;

15 нче пункттагы «Үткәрелгән тикшерүләр» дигән сүзләрдән соң «, мәдәни мирас объектлары торышын тикшерүдә тоту чаралары һәм системалы күзәтү» дигән сүзләрне өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\863.docx